КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 18 июль г.Казань № 689

2021 елда педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларына премияләр бирү конкурсында җиңүче укытучылар эшли торган гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә 2022 елда бер тапкыр бирелә торган түләү турында

Мәгариф лидерларына ярдәм күрсәтү, алдынгы идарә итү һәм педагогик тәҗрибәне тарату, белем бирү сыйфатын яхшырту һәм Татарстан Республикасы педагогик хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елда педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларына премияләр бирү конкурсында җиңүче укытучылар эшли торган гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә 2022 елда 30 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләү (алга таба шул ук эзлеклелектә – бер тапкыр бирелә торган түләү, Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре) билгеләргә.

2. Бер тапкыр бирелә торган түләү Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирә торган мәгариф программалары гамәлгә ашырыла торган мәгариф оешмаларының педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен премияләр түләнә торган укытучылары исемлеген раслау турында» 2021 елның 11 августындагы 547 номерлы боерыгы белән расланган Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирә торган мәгариф программалары гамәлгә ашырыла торган мәгариф оешмаларының педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен премияләр түләнә торган укытучылары исемлегенә укытучылары кертелгән Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә бирелә дип билгеләргә.

3. Бу карарны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2021 елның 25 ноябрендәге 86-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында әлеге максатлар өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына 60 көн эчендә 2021 елда педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларына премияләр бирү конкурсында җиңүче укытучылар эшли торган гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә бер тапкыр бирелә торган түләү бирү тәртибен эшләргә һәм расларга.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елда педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларына премияләр бирү конкурсында җиңүче укытучылар эшли торган гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә 2021 елда бер тапкыр бирелә торган түләү турында» 2021 ел, 19 август, 749 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин